ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2 ноябрь, 2022 ел № 17/9

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты структурасына үзгәрешләр кертү турында аерым карарларга үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизацияләү турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы 8 өлеше, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 40 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1.Шәһәр Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 34/7 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты структурасына (Шәһәр Советының 2016 елның 7 апрелендәге 7/15, 2016 елның 18 маендагы 8/6, 2016 елның 8 июлендәге 9/11, 2020 елның 28 маендагы 39/7, 2020 елның 29 декабрендәге 4/6, 2022 елның 22 августындагы 16/11 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 10 пунктчаны көчен югалткан дип танырга;

2) түбәндәге эчтәлектәге 25.3, 25.4 пунктларны өстәргә:

«25.3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының мобилизация бүлеге;

25.4) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе».

2. Шәһәр Советының 2008 елның 13 декабрендәге 36/9 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрының 3 бүлегенә (Шәһәр Советының 2011 елның 14 апрелендәге 11/6, 2012 елның 20 декабрендәге 22/16, 2013 елның 29

августындагы 26/15, 2021 елның 9 декабрендәге 10/8 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге эчтәлектәге 10 абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«- мөстәкыйль бүлекчә мөдире.»

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ